РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ТИХОНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423655 Менделеевский район, с. Тихоново, ул. Шишкина д. 3А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТИХОНОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423655 Менделеевск районы, Тихоново авылы, Шишкин урамы, 3А

тел./факс (85549)3-43-62 Email: Tihon.Men@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

19.04. 2023 ел № 8

**Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Тихоново авыл җирлеге Советының 2023 елның
20 мартындагы 5 номерлы карарын
гамәлдән чыккан дип тану турында**

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4.2 өлеше һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 8 өлеше нигезендә «Муниципаль хезмәт турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2023 елның 17 мартындагы 10/13-13 номерлы аңлатмалары нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл җирлеге Советының 2023 елның 20 мартындагы 5 номерлы карарын гамәлдән чыккан дип санарга
2. Әлеге карарны Ижевка авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмати стендларга, шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына урнаштырып игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында Тихоново авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга www.mendeleevsk.tatar.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Тихоново авыл җирлеге советы рәисе А. М. Карманов